РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
СОВЕТ
ЧЕРКИ-КИЛЬДУРАЗСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КИЛДУРАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**КАРАР**
**РЕШЕНИЕ**

“21” апрель 2016ел № 12-1

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Килдураз авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Килдураз авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 08 июлендәге 613 номерлы «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре» Указы, «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» 2010 елның 11 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Килдураз авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Расларга:

- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Килдураз авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар

тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Килдураз авылы җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне (1 нче кушымта);

- Гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, һәм аларны биләгән затлар үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тәкъдим итәргә тиешле Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлегендә муниципаль вазифалар исемлеге (2 нче кушымта).

2. Әлеге карар имзаланганнан соң законлы көченә керә һәм Буа муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Килдураз
авыл җирлеге башлыгы М.В. Җәлялтдинов

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Килдураз авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Килдураз авылы җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмә

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 73-ФЗ номерлы, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 08 июлендәге 613 номерлы «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре» Указы, «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» 2010 елның 11 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы Указы нигезендә әлеге Нигезләмә белән түбәндәгеләрне бирү карала:

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Килдураз авыл җирлегендә (алга таба шулай ук - район) муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан аларның алынган керемнәре (керемнәре күләме һәм чыганаклары турында), милек хокукындагы яисә башка хокук нигезендә файдаланудагы мөлкәтләре турында, мөлкәти характердагы башка йөкләмәләре (алга таба шулай ук - керемнәр турында белешмәләр), шулай ук аларның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында белешмәләр;

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Килдураз авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, керемнәр турында, алар хисабына җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары хакында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса, һәм әлеге алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында (алга таба - чыгымнар турында белешмәләр), шулай ук аларның керемнәре, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында белешмәләр булса.

2. Әлеге Нигезләмәдә каралган муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар дигәндә, җирле үзидарәнең сайланулы органнары депутатлары, әгъзалары, авыл җирлеге Советы карары белән расланган исемлек нигезендә район җирле үзидарә органнарының сайланулы вазыйфаи затлары аңлашыла.

3. Керемнәр турында белешмәләрне авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тапшыра.

Авыл җирлеге Советы карары белән расланган исемлектә каралган муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар керемнәр, чыгымнар турында белешмәләр тапшыра.

4. Керемнәр турында (керемнәр күләме турында һәм чыганаклары хакында) белешмәләр, район Советы депутатына кандидат, район Советы депутаты статусы буенча биләгән муниципаль вазыйфага кандидат йә җирле үзидарәнең башка сайланулы органында турыдан-туры сайлаулар юлы белән биләгән вазыйфага яисә әгъзалыкка кандидат тарафыннан “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - 67-ФЗ номерлы Федераль закон) каралган форма буенча авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан тапшырыла.

5. Авыл җирлеге Советы карары белән расланган исемлектә каралган муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар турында белешмәләр, 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указ белән расланган белешмә формасында, ел саен хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

6. Муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы граждан 67-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда барлык чыганаклардан алынган керемнәрнең күләме һәм чыганаклары турында (элекке эш урыны яисә сайланулы вазыйфаны биләү урыны буенча керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) белешмәләр, шулай ук ул милек хокукындагы мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне тапшыра.

7. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат ел саен түбәндәгеләрне тапшыра:

1) хисап чорына алынган керемнәре (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) турында барлык чыганаклардан (акчалата бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) алынган белешмәләр, шулай ук хисап чоры ахырына торышы буенча милекчелек хокукындагы яисә башка хокуктан файдаланудагы мөлкәт турында белешмәләр, мөлкәти характердагы башка йөкләмәләр;

2) хисап чорында алынган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр; хисап чорында балигъ булган балигъ булмаган балалар өчен - балигъ булу яше җиткән) барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) белешмәләр, шулай ук хисап чоры ахырына торышы буенча милек хокукында яисә башка хокукта файдаланудагы мөлкәте турында белешмәләр, мөлкәти характердагы башка йөкләмәләр;

3) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре), әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артыграк булса, үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр

8. Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында каралган муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы гражданнар керемнәре турында белешмәләр 67-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә һәм срокларда тиешле сайлау комиссиясенә тапшырыла.

9. Муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы гражданнар керемнәре турында белешмәләр Буа муниципаль районы авыл җирлеге советына тапшырыла.

10. Муниципаль вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы граждан үзләренә тапшырылган белешмәләрдә күрсәтелмәгән яисә нинди дә булса белешмәләр тулысынча чагылдырылмаган йә хаталар булган очракта, ул муниципаль вазыйфаны биләү турындагы

мәсьәләне (кандидатны теркәү турындагы мәсьәлә хәл ителергә тиешле сайлау комиссиясе утырышы) карау көненә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы.

11. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга мөмкин.

12. Муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү кануннар нигезендә гамәлгә ашырыла.

13. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат объектив сәбәпләр аркасында муниципаль вазыйфа, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмаган очракта, әлеге факт Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының тиешле комиссиясе тарафыннан каралырга тиеш.

14. Муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырыла торган белешмәләр, әгәр федераль закон белән алар дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләргә кертелмәгән булса, конфиденциаль характердагы белешмәләр була.

Әлеге белешмәләр федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда вазыйфаи затларга бирелергә мөмкин.

15. Муниципаль вазыйфаны, аның хатынын (хатынын) һәм балигъ булмаган балаларын законнарда каралган тәртиптә биләүче затның керемнәре һәм чыгымнары турындагы белешмәләр муниципаль берәмлекнең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла, ә бу белешмәләр булмаганда, муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында аларның гарызнамәләре буенча бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла.

16. Вазыйфаи бурычларына муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырыла торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр белән эш итү керә торган авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары затлары арасыннан булган, әлеге белешмәләрне фаш итүдә яисә законнарда каралмаган максатларда файдалануда гаепле затлар, шулай ук дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган белешмәләрне таратуда гаепле затлар законнар нигезендә җаваплы булалар.

17. Муниципаль вазыйфа (муниципаль вазыйфага билгеләнү, сайлану) буенча вәкаләтләр бирелгән очракта муниципаль вазыйфаны биләүгә дәгъва итүче тарафыннан тапшырылган керемнәр турында белешмәләр, ел саен тапшырыла торган керемнәр һәм чыгымнар турында белешмәләр, шулай ук әлеге белешмәләрнең дөреслеген тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат һәм тулылыгын муниципаль вазыйфаны биләүче затның шәхси эшенә кушып бирелә.

Керемнәр турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында белешмәләр биргән граждан муниципаль вазыйфа буенча вәкаләтләр бирелмәгән булса, тиешле документлар (белешмәләр) аңа язма гариза буенча кире кайтарыла.

18. Муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы керемнәр турында ялган белешмәләр тапшырмау (срокны бозып тапшыру) яисә ялган белешмәләр тапшыру әлеге затны муниципаль вазыйфага дәгъва кылучы буларак теркәүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

19. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат керемнәре, чыгымнары турында ялган (срогын бозып тапшыру) яисә тулы булмаган, дөрес булмаган, шул исәптән ялган белешмәләр, законнарда каралган җаваплылыкка, шул исәптән биләгән вазыйфасыннан азат ителүне законнарда билгеләнгән тәртиптә азат итүгә китерә.

2 нче кушымта

Гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә хатынының (иренеӊ) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренеӊ) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, һәм аларны биләгән затлар үз хатынының (иренеӊ) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренеӊ) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тәкъдим итәргә тиешле Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлегендә муниципаль вазифалар исемлеге

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Совет рәисе, Килдураз авыл җирлеге башлыгы

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Килдураз авыл җирлеге Советы депутатлары